| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**27.06.2016** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 103** |

Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 31 мартындагы 376 номерлы карары белән расланган «2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.Р.Кадникованың Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 31 мартындагы 376 номерлы карары белән расланган «2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы кушымтасына үзгәрешләр кертү турында, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон,  Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 9 сентябрендәге 659 номерлы «2014-2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары белән расланган “2014-2016 елларга Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советы 2014 елның 31 мартындагы 376 номерлы карары белән расланган «2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында», «2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) I бүлекнең 4 графасының 7 пунктында «2015» саннарын «2016»

саннарына алмаштырырга;

2) II бүлекнең 1 пунктындагы 2 һәм 5 графаларындагы «муниципаль хезмәткәрләр» сүзләреннән соң «һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**